ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ГОРОДА
ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район,
Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС
ШӘҺӘРЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | | КАРАР |
|---|---|---|
| 17.12.2025 | Иннополис шәһәре | 105 |

2026 елга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль кысаларында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 51 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Законда саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасын контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 25 июнендәге 990 номерлы карары нигезендә, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль кысаларында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасын расларга.

2. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә һәм рәсми хокукый мәгълүмат порталында https://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук муниципаль берәмлекләр порталына мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Интернетта https://verhniy-uslon.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Иннополис шәһәре Мэриясе бинасында урнашкан мәгълүмат стендында игълан ителергә тиеш.

3. Әлеге карарны үтәүне контрольдә тоту Иннополис шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, төзелеш һәм архитектура бүлеге начальнигы А.А. Багавиевка йөкләнергә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.Ф.Ханбиков

Иннополис шәһәре Башкарма
комитетының
2025 елның 17 декабре
№ 105 карарына
Кушымта

## 2026 елга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль кысаларында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын профилактикалау программасы

2026 елга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль кысаларында закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын профилактикалауның әлеге программасы (алга таба - Программа) оешмалар һәм гражданнар тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең намуслы үтәлешен стимуллаштыру, мәҗбүри таләпләрне бозуга һәм (яисә) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерергә мөмкин булган шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү, контрольдә тотылучы затларга мәҗбүри таләпләрне җиткерү өчен шартлар тудыру, аларны үтәү ысуллары турында хәбәрдарлыкны арттыру максатларында эшләнгән.

Әлеге Программа эшләнде һәм Иннополис шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан (алга таба текст буенча - Башкарма комитет) үтәлергә тиеш.

### 1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның агымдагы торышын анализлау, контроль органының профилактик эшчәнлегенең агымдагы үсешен тасвирлау, Программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблемаларга характеристика

1.1. Муниципаль контроль төре: Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль 2026 елга (алга таба текст буенча – Иннополис шәһәре).

1.2. Иннополис шәһәре территориясендә муниципаль контроль предметы булып гражданнар һәм оешмалар (алга таба - контрольдә тотыла торган затлар) тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлеше тора:

1) янәшәдәге территорияләрне карап тоту буенча;

2) төзекләндерү элементлары һәм объектларын карап тоту буенча;

3) шәһәр территориясен кышкы чорда җыештыру буенча, шул исәптән биналарның, корылмаларның түбәләрен кардан, каткан боз һәм боз сөңгеләреннән чистарту чараларын үткәрүне дә кертеп;

4) шәһәр территориясен җәйге чорда җыештыру буенча, шул исәптән карантин, агулы һәм чүп үләннәрен ачыклау, аларга каршы көрәш, аларны локальләштерү, бетерү буенча мәҗбүри таләпләрне дә кертеп;

5) янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда янгын куркынычсызлыгының өстәмә таләпләре;

6) гомуми файдаланудагы территорияләрдә җир асты коммуникацияләрен салу, яңадан урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту буенча мәҗбүри таләпләр;

7) әгәр мондый документлар (кисү билеты, күчереп утыртуга рөхсәт) төзекләндерү кагыйдәләрендә билгеләнгән очракларда бирелергә тиеш булса, яшел үсентеләрне утырту, саклау һәм карап тоту буенча мәҗбүри таләпләр, шул исәптән агачларны һәм куакларны кисү билеты һәм (яисә) агачларны һәм куакларны күчереп утыртуга рөхсәт нигезендә агачларны һәм куакларны бетерү (казып алу), күчереп утырту буенча мәҗбүри таләпләр;

8) каты коммуналь калдыкларны туплау буенча мәҗбүри таләпләр.

Контроль чаралар нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларны үтәү дә муниципаль контроль предметы булып тора.

Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү (зарар) куркынычын профилактикалау кысаларында түбәндәге чаралар планлаштырыла:

- Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Порталында веб-адрес буенча: https://verhniy-uslon.tatarstan.ru/ мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә «Интернет» мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актларның яки аларның аерым өлешләренең исемлекләрен, муниципаль контроль предметы булып торган таләпләрнең үтәлешен бәяләү, шулай ук тиешле норматив хокукый актларның текстларын урнаштыру.

- мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыру, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча кулланмалар эшләү һәм бастыру, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре алып бару;

- муниципаль контрольне гамәлгә ашыру практикасын даими гомумиләштерүне тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Порталында веб-адрес буенча: https://verhniy-uslon.tatarstan.ru/ мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә «Интернет» гомумиләштерүләрне урнаштыру, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне бозу очракларының иң еш очрый торганнары белән юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мондый бозуларны булдырмау максатында кабул ителергә тиешле чараларга карата тәкъдимнәр белән;

- «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясындагы 5-7 өлешләре нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр бирү.

## 2. Профилактик эшнең максатлары

2.1. Профилактика программасының максатлары түбәндәгеләр:

а) контрольдәге субъектлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозуны кисәтү, мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бетерүне дә кертеп;

б) контрольдә тотылырга тиешле субъектларга административ йөкләнешне киметү;

в) контрольдә тотучы субъектларның үз-үзләрен намуслы тотышына мотивация булдыру;

г) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә китерелә торган зыян (вред) дәрәҗәсен киметү.

3. Профилактик эшнең бурычлары

3.1. Мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау системасын ныгыту;

3.2. Мәҗбүри таләпләрне бозуларга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны ачыклау, мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерүгә юнәлдерелгән чаралар эшләү;

3.3. Карала торган хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә оешмаларның һәм гражданнарның хокукый аңын һәм хокукый культурасын арттыру.

Контроль төре турындагы нигезләмәдә намуслы контрольдә тотылучы затларны матди булмаган бүләкләүгә юнәлдерелгән чаралар билгеләнмәгән, димәк, программада намуслылыкны стимуллаштыру чаралары каралмаган.

Контроль төре турындагы нигезләмәдә мәҗбүри таләпләрне үтәүне мөстәкыйль бәяләү (үз-үзеңне тикшерү) каралмаган, димәк, программада автоматлаштырылган режимда үз-үзеңне тикшерү ысуллары билгеләнмәгән («Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 51 ст. 1 өлеше).

4. Профилактик чаралар исемлеге, аларны уздыру сроклары (вакыты)

| № т/б | Чараның атамасы | Чараны гамәлгә ашыру вакыты | Җаваплы вазифаи зат |
|---|---|---|---|
| 1. | Мәгълүмат бирү Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Порталында тиешле белешмәләр урнаштыру юлы белән мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча гамәлгә ашырыла | Даими рәвештә | Торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, төзелеш һәм архитектура бүлегенең торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү буенча баш белгече |
| 2. | Хокук куллану практикасын гомумиләштерү контроль чаралары | Ел саен хокук куллану | Торак-коммуналь |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | үткәрү һәм аларның нәтиҗәләре турында мәгълүмат җыю һәм анализлау юлы белән башкарыла.<br>Хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләрен үз эченә алган доклад әзерләнә, ул контроль орган җитәкчесе тарафыннан раслана һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Порталында урнаштырыла (https://verhniy-uslon.tatarstan.ru/) | практикасын гомумиләштерү елыннан соң килгән елның 30 гыйнварыннан да соңга калмыйча. | хуҗалык, төзекләндерү, төзелеш һәм архитектура бүлегенең торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү буенча баш белгече |
| 3. | Кисәтү игълан итү.<br>Мәҗбүри таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү, мәҗбүри таләпләрне бозу әзерләнүе турында мәгълүматлар булган очракта һәм (яисә) мәҗбүри таләпләрне бозу закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китергән яки закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы тудырган дигән мәгълүматлар расланмаган очракта, контрольдә тотыла торган затка игълан ителә. | Законнарда каралган нигезләр барлыкка килгән саен | Иннополис шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, төзелеш һәм архитектура бүлеге начальнигы<br><br>Торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, төзелеш һәм архитектура бүлегенең торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү буенча баш белгече |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4. | Консультация бирү.<br>Консультация телдән яки язма рәвештә, телефон аша, видео-конференц элемтәсе ярдәмендә, шәхси кабул итүдә, профилактик чара үткәрү барышында, контроль (күзәтчелек) чарасы вакытында башкарыла. | Контрольдәге затлар һәм аларның вәкилләре мөрәҗәгатьләре буенча даими рәвештә | Торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, төзелеш һәм архитектура бүлегенең торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү буенча баш белгече |
| 5. | Профилактик визит | Кварталга бер тапкыр | Торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, төзелеш һәм архитектура бүлегенең торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү буенча баш белгече |

5. Программаның нәтиҗәлелеге һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре

| № т/б | Күрсәткеч исеме | Зурлык |
|---|---|---|
| 1. | «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2021 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 3 өлеше нигезендә контроль органның «Интернет»челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган мәгълүматның тулылыгы | 100% |
| 2. | Докладны раслау, муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләрен үз эченә алган, аны бастырып чыгару. | Башкарылган / Башкарылмаган |
| 3. | Әзерләнә торган мәҗбүри таләпләрне бозулар яисә мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында | 20% һәм аннан күбрәк |

| | | |
|---|---|---|
| | расланган белешмәләр булган мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча һәм мәҗбүри таләпләрне бозуның закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүе йә закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы тудыруы турында расланган мәгълүматлар булмаган очракта кисәтүләр өлеше ( % ) | |
| 4. | Консультация сорап мөрәҗәгать иткән затларның гомуми санында консультация бирүдән канәгать булган затлар өлеше | 100% |